ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУТЛЕРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Школьная ул., д.12,с.Мокрые
Курнали,422917

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БУТЛЕРОВКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп ур., 12нче йорт, Юеш
Бутлеровка авылы, 422917

Тел.8(84341) 32-6-25, факс 8(84341) 32-6-24, E-mail: Btlr.Alx@tatar.ru,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«30» июля 2024 г. № 16

**«Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4 августындагы 19 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 05 февралендәге 124 номерлы карарына, «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.08.2021 ел, №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.2 пунктның 10 абзацында «Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «Гариза белән» сүзләренә алмаштырырга.;

- 1.5 пунктның 9 абзацында «(шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы),» сүзләреннән соң «яр буе,» сүзен өстәргә.;

- 1.5 пунктның 10 абзацында «яр буе,» сүзен төшереп калдырырга;

- 2.3.2 пунктта «вәкаләтле орган карары буенча берләштерелергә мөмкин» сүзләрен «берләштерелә» сүзенә алмаштырырга;

- 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Адреслаштыру объектына адрес бирү яисә аның адресын юкка чыгару турында карар, адреслаштыру объектына адрес бирүдән баш тарту яисә аның адресын юкка чыгару турында карар кабул итү, шулай ук адреслаштыру объектының адресы турында тиешле белешмәләр урнаштыру дәүләт адреслар реестрында вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла:

а) гариза кәгазьдә бирелгән очракта-гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта - гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәгеТатарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Бутлеровка авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Л. Хушанова**